ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**БОЕРЫК**

29.11.2021__________ № 223-од________

Казан ш.

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2016 елның 14 октябрендәге 091-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 8 ноябрендәге 1058 номерлы карары нигезендә

боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2016 елның 14 октябрендәге 091-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 27 октябрендәге 136-од номерлы, 2019 елның 3 июнендәге 125-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г. З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы
Архив эше буенча дәүләт
комитетының 2021 елның
29 ноябрендәге 223-од
номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2016 елның 14 октябрендәге 091-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Иҗтимагый Советының бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

архив эше өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүдә катнашу;

ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты карарларын кабул иткәндә җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең хәбәрдар булуын арттыру;

җәмгыятьтә коррупциягә карата түзә алмаучылык булдыру.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.5 пункт өстәргә:

«2.5. Күрсәтелгән максатларга һәм куелган бурычларны хәл итүгә ирешү өчен Иҗтимагый совет:

архив эше өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

коррупциягә каршы көрәш эшчәнлегендә катнаша;

«Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Иҗтимагый совет утырышында алдан каралмыйча кабул ителә алмаган ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза ясауны оештыра;

ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфатына мониторинг ясауда катнаша;

ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының дәүләт сатып алулары нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча конкурс комиссияләре һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренә аттестация үткәрү өчен аттестация комиссияләре эшендә катнаша.»;

3 бүлектә:

3.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Иҗтимагый Совет әгъзаларының вәкаләтләре срогы яңа төзелгән Иҗтимагый совет составының беренче утырышын уздырган көннән соң өч ел тәшкил итә.»;

3.6 – 3.8 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме буенча ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы нигезендә түбәндәге очракларда туктатыла:

Россия Федерациясенең җинаять-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә аңа җинаять кылуда гаепләү белдерелгәндә;

аңа административ кулга алу рәвешендә административ җәза билгеләнгәндә;

ул дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы депутатына кандидат, җирле үзидарә органында сайланулы вазыйфага кандидат, сәяси партиянең ышанычлы заты яисә вәкаләтле вәкиле буларак теркәлгәндә, шулай ук ул Россия Федерациясендә референдум үткәрү буенча инициатив төркем составына кергән очракта;

әлеге Типлаштырылган нигезләмәнең 6.6 пунктында каралган нигезләр булганда.

3.7. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

аның вәкаләтләре чоры тәмамланганда;

Иҗтимагый совет составыннан чыгу турында аның тарафыннан гариза тапшырылганда;

сәламәтлеге торышы буенча Иҗтимагый совет эшендә катнаша алмаганда;

аңа карата чыгарылган суд хөкеме законлы көченә кергәндә;

законлы көченә кергән суд карары нигезендә ул хокукый сәләтсез яисә хәбәрсез юкка чыккан дип танылганда;

этика нормалары аның тарафыннан тупас бозылганда – утырышта катнашучы Иҗтимагый совет әгъзалары саныннан тавыш күпчелеге белән кабул ителгән Иҗтимагый совет карары буенча;

Иҗтимагый совет утырышлары эшендә системалы рәвештә (өч тапкырдан күбрәк) җитди сәбәпләрсез катнашмаганда;

Ижтимагый совет рәисе яисә рәисе урынбасары йөкләмәләрен системалы рәвештә (ике тапкырдан артык) җитди сәбәпләрсез үтәмәгәндә;

ул Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына, Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт вазыйфасына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына, муниципаль вазыйфага яисә муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелганда;

ул чит ил гражданлыгын (подданныйлыгын) алганда;

Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда;

Ижтимагый совет әгъзасының мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китерә алган шәхси мәнфәгатьләре барлыкка килгәндә.

3.8. Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату Иҗтимагый совет әгъзасының язма гаризасы яисә Иҗтимагый совет рәисе тәкъдиме нигезендә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган хәлләрнең булуы ачыкланган очракта, ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән гамәлгә ашырыла.

Иҗтимагый совет әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктындагы дүртенчеPar9, бишенче, унынчы – уникенче абзацларында каралган хәлләр барлыкка килү турында Иҗтимагый совет рәисенә хәбәр итәргә тиеш.

түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр каршылыгы

6.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы – Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси мәнфәгате аның үз бурычларын тиешенчә, объектив һәм намуслы үтәвенә (вәкаләтләрне гамәлгә ашыруына) йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган һәм шул ук вакытта Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси мәнфәгате һәм Иҗтимагый совет максатлары, бурычлары арасында каршылык барлыкка китерә торган яисә барлыкка китерә алган вәзгыять.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үз вәкаләтләрен объектив һәм намуслы гамәлгә ашыруына йогынты ясый яки йогынты ясый ала торган шәхси мәнфәгате дигәндә Иҗтимагый совет әгъзасының акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар йә үзләре өчен яки өченче затлар өчен хезмәт күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы барлыкка килгән мәнфәгатьләр каршылыгы турында яки аның барлыкка килү ихтималы хакында аңа моның турында билгеле булуга язма рәвештә ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисенә хәбәр итәргә, ә Иҗтимагый совет рәисе бу хакта язма рәвештә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына хәбәр итәргә тиеш.

Иҗтимагый совет рәисе мәнфәгатьләр каршылыгының барлыкка килүе яисә аның барлыкка килү ихтималы булу турында язма рәвештә ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына аңа бу хакта билгеле булуга хәбәр итәргә тиеш.

6.4. Иҗтимагый совет әгъзасының мәнфәгатьләр каршылыгына китерә торган яисә китererә алган шәхси мәнфәгате барлыкка килүе турында билгеле булган Иҗтимагый совет яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә аны җайга салу буенча чаралар күрергә, шул исәптән Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасында билгеләнгән тәртиптә ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисенә мәнфәгатьләр каршылыгының бер ягы булып торучы Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору яисә туктату турында тәкъдим кертү юлы белән, тиеш.

6.5. Иҗтимагый совет яки Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Иҗтимагый совет эшчәнлегендәге коррупциягә кагылышлы куркынычларның булу-булмавын бәяли һәм коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә Иҗтимагый совет әгъзаларының катнашуын булдырмау максатларында аларны минимальләштерү чараларын күрә.

Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә Иҗтимагый совет әгъзасының катнашу факты турында билгеле булган Иҗтимагый совет рәисе бу хакта язма рәвештә ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына өч эш көне эчендә хәбәр итә.

Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашуы факты билгеле булган Иҗтимагый совет әгъзалары бу хакта язма рәвештә ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисенә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына өч эш көне эчендә хәбәр итә.

6.6. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә Иҗтимагый совет әгъзасының катнашуы факты турында мәгълүмат алган очракларда, Иҗтимагый совет эшендә Иҗтимагый совет әгъзасының катнашуын туктатып тору турында Дәүләт комитеты рәисенә тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору турында ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе карары ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый совет әгъзасының мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүенә китерә торган хәлләр бетерелмәгән йә Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашуы факты расланган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисенә Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату турында тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен туктату турында ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе карары ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый совет әгъзасының мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүенә китерә торган хәлләр бетерелгән (расланмаган) һәм (яисә) Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашуы факты расланмаган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисенә Иҗтимагый совет әгъзасының вәкаләтләрен яңадан торгызу турында тәкъдим кертә.

Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен яңадан торгызу турында ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе карары ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән расланырга тиеш.».